ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 4-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Е.Б. Солтанов, А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 4-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 27 сентябре
№ 64-VII ДС

4-7 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Е.Б Солтанов
А.Г. Хәбибуллин,
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 44 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $10^7$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«$10^7$ статья. **Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булган депутатның Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү**

Депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булган депутатның Россия Федерациясеннән чыгу хокукы вакытлыча чикләнергә мөмкин.

Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булган депутатның Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан кабул ителә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) «Россия Федерациясеннән чыгу һәм Россия Федерациясенә керү тәртибе турында» 1996 елның 19 августындагы 114-ФЗ номерлы Федераль законны (алга таба – 114-ФЗ номерлы Федераль закон) гамәлгә ашыру максатларында әзерләнде.

Федераль законның 15 статьясы нигезендә Россия Федерациясе гражданының Россия Федерациясеннән чыгу хокукы, әгәр ул аерым әһәмияттәге белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән файдалана алган булса, вакытлыча чикләнергә мөмкин.

Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булган Россия Федерациясе субъектлары закон чыгару органнары депутатларының Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында карар Россия Федерациясе субъекты закон чыгару органы билгели торган тәртиптә Россия Федерациясе субъекты закон чыгару органы рәисе тарафыннан кабул ителә.

Закон проектында аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының Россия Федерациясеннән чыгу хокукы вакытлыча чикләнергә мөмкин дип карала.

Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булган депутатның Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан кабул ителә.

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә аерым әһәмияттәге белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында карар кабул итү тәртибен раслау хакындагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын кабул итү таләп ителәчәк.

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.